Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина

# ГОМУМИ УРТА БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕН ТУГАН ТЕЛ БУЛАРАК ӨЙРӘНҮЧЕ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕН КАЛЕНДАРЬ-ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

(яки татар әдәбиятын укытуның кыскартылган варианты)

8 нче сыйныф
Аңлатма язуы

Татар әдәбияты дәресләренең төп бурычлары:
- татар әдәбияты тарихының төп фактларына нигезләнеп, әдәби әсәрне уку һәм анализлау күнекмәләре формалаштыру;
- матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку ихтыяҗы булдыру;
- укучыларның телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерү;
- татар халкына, аның әдәбияты һәм мәдәниятенә хөрмәт, дөньяга гуманлы караш, башка халыкларның мәдәниятләре белән кызыксыну тәрбияләү.

*8 нче сыйныфта татар әдәбияты фәне кимендә атнага 2 сәгатьтән ел буена 68 сәгать укытылырга тиеш. Нәкъ шул очракта гына әдәбият предметы буенча куелган максатларга өлешчә булса да ирешергә мөмкин. Әдәбиятны 68 сәгать күләмендә өйрәтү методикасы тулы күләмдә алда исемнәре күрсәтелгән әсбапларда, бәйнә-бәйнә, тәфсилләп, һәр дәресләп, дәрестә этаплап, минутлап һәм тасвирлап аңлатылды. Методик әсбапларны Казан шәһәрендә, Ямашев проспектындагы 51-71 нче офистан теләсә кайсы көндә сатып алырга була. "Мәгариф-Вакыт" нәшриятының үз сайты бар, телефоннары эшләп тора. (http://magarif-vakyt.ru E-mail: valeevmx@mail.ru) Соңгы вакытларда мәктәпләрнең күпчелегендә татар әдәбияты атнага берәр сәгатьтән, елга 34 сәгать күләмендә планлаштырыла. Предмет буенча әлеге тематик план шул очракны гына искә алып төзелде. Әдәби материалның яртысын, эчтәлеккә зыян китермичә, тулысынча кыскарту әдәбиятны укыту кануннарына берничек тә туры килә алмый. Кайбер дәресләрдә укытучының әдәби материалны төркемләп тә бүлеп бирүе күз алдында тотылды.*

Гомуми урта белем бирү оешмалары өчен Татар әдәбиятыннан программа Россия Федерациясенең "Мәгариф турында"гы Законы (7 нче маддә), Россия Федерациясе хөкүмәте раслаган (2001 нче ел, 29 нчы декабрь, №1756) "Россия мәгарифен яңарту Концепциясе", Татарстан Республикасының "Мәгариф турында"гы Законы, "Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" Татарстан Республикасы Законы (9 нчы маддә) кебек норматив документларга һәм татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандартларына нигезләнеп эшләнде.

**Эш программасын төзү өчен материал исемлеге:**

1. **Дәреслек:**
Хәсәнова, Ф.Ф. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 8 нче с-ф. Ике кисәктә / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина, Ә.Н.Сафиуллина; [рәссамы Фәридә Ризаева]. – Казан: "Мәгариф–Вакыт" нәшр., 2015. – 175 б, 151 б.

2. **Электрон дәреслек:**
Хәсәнова, Ф.Ф. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 8 нче с-ф. Ике кисәктә / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. Ә.Н.Сафиуллина; [рәссамы Фәридә Ризаева]. – Казан: "Мәгариф–Вакыт" нәшр., 2015.

3. **Методик ярдәмлек:**
Хәсәнова, Ф.Ф. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән) эшләүче укытучылар өчен методик әсбап. 8 нче с-ф. / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина, Ә.Н.Сафиуллина. – Казан: "Мәгариф–Вакыт" нәшр., 2015. – 223 б.

4. **Эш дәфтәре (һәр укучы өчен контроль-диагностика материаллары)**
Хәсәнова Ф.Ф. Һәр дәрескә тестлар: диагностика буенча эш дәфтәре. 8 нче сыйныф / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан: "Мәгариф–Вакыт" нәшр., 2016. – 111 б.

5. **Сочинение язарга өйрәтү ярдәмлеге**
Хәсәнова Ф.Ф. Сочинение язарга өйрәтәбез: укытучылар өчен методик кулланма / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан: "Мәгариф–Вакыт" нәшр., 2016. – 159 б.

6. **Авторлык программасы**

Хәсәнова, Ф.Ф. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен татар әдәбиятыннан авторлык программасы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 5–9 сыйныфлар. Яңартылган, тулыландырылган, төзәтелгән 2 нче басма / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан: “Мәгариф–Вакыт” нәшр., 2016. – 63 б.

**8 НЧЕ СЫЙНЫФ ӨЧЕН**
**КАЛЕНДАРЬ-ТЕМАТИК ПЛАН**

| Дә-рес № | Дәрес темасы | Дәрес саны | Көтелгән нәтиҗә | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Контроль эш төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | план | факт |
| 1. | Л. Шагыйрьҗан. “Мәктәпкә мәдхия” шигыре | 1 | Шигырьнең темасын проблемасын билгеләү. Укырга теләк уяту | Сәнгатьле уку, шигырьне анализлау. | тест | | |
| **Халык авыз иҗаты** | | | | | | | |
| 2. | Бәет жанры. “Сөембикә бәете” “Уңмаган килен бәете”, “Рус-француз сугышы бәете” | 1 | Халык авыз иҗаты әсәрләреннән бәетләр белән танышу. Халкыбызның тарихи үткәне турында белем бирү. Бәетләр белән танышуны дәвам итү | Сәнгатьле уку, бәетне анализлау Бәетләрне сәнгатьле уку | тест | | |
| 3. | Равил Фәйзуллин. “Пароход бәете” Мөнәҗәтләр. “Мөнәҗәтем, бәнем бетмәс...” | 1 | Бүгенге көндә дә бәетләр чыгару дәвам иткәнлегенә инандыру. Бәетнең эчтәлеген ачу. Авторның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә бирү. “Болгария” теплоходы фаҗигасе турында искә төшерү. Бүгенге көн һәм элек иҗат ителгән бәетләр турында сөйләшү | Шагыйрь Р. Фәйзуллин турында белгәнннәрне искә төшерү. Бәетне уку. ”Пароход бәете”нең алда өйрәнгән бәетләрдән аермалы якларын билгеләү. Бәеттә телгә алынган фактлардан чыгып, вакыйганы сөйләү | тест | | |
| 4 | Э.Шәрифуллина. “Ата хакы, ир хакы” мөнәҗәте, Л.Шагыйрьҗан. “Мөнәҗәт тыңлаганда”, Ф. Сәләхов. “Мөнәҗәт турында фикерләр” | 1 | Гореф-гадәт, йолаларга ихтирам тәрбияләү, аларны саклау | “Пароход бәете”нең алда өйрәнгән бәетләрдән аермалы якларын билгеләү | тест | | |
| **Борынгы әдәбият үрнәкләре** | | | | | | | |
| 5 | Гаруз шигырь системасы һәм газәл жанры. Р. Гаташ. “Газәл”, М. Мирза. “Газәл” | 1 | Гаруз шигырь системасы, газәл жанры турында мәгълүмат бирү | Теоретик материал белән танышу. Сорауларга җавап эзләү, әсәрне ишетеп аңлау | тест | | |
| **XIX йөз әдәбияты** | | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | XIX йөз әдәбияты. Акмулланың тормыш юлы һәм иҗаты<br>М. Әгъләмов. “Акмулла арбасы” поэмасы. Акмулла бәете. | 1 | XIX йөз әдәбияты турында аңлату. Акмулланың тормыш юлы һәм иҗатына күзәтү ясау.<br>Акмулла яшәгән чор турында тарихи белешмә бирү | XIX йөз әдәбияты схемасы буенча эш. Автор әйтергә теләгән фикерне табу, әдәби әсәр турында фикер алышу | тест | | |
| **XX йөз башы әдәбияты** | | | | | | | |
| 7 | Г. Тукайның Казан чоры иҗатына күзәтү. “Пар ат” шигыре. “Пар ат” шигыре турында | 1 | Шагыйрьнең Казан чоры иҗатына күзәтү ясау. “Пар ат” әсәрен өйрәнү | Сүзлек белән эш, фронталь әңгәмә, парлы эш, үз фикерләрен текст белән раслау | тест | | |
| 8 | Г. Тукайның “Бер татар шагыйренең сүзләре” шигыре | 1 | Г. Тукай иҗаты белән танышуны дәвам итү | Әсәрне сәнгатьле уку, сораулар буенча эчтәлекне ачыклау | тест | | |
| 9-10 | Г.Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты. “Алмачуар” хикәясе. Р. Харис. “Алмачуарның һәлак булуы хакында” | 2 | Г. Ибраһимов иҗаты турында белешмә. “Алмачуар” әсәрен өйрәнү. Р. Харисның әсәргә карата әйтелгән фикерен белү | Әсәр эчтәлеге белән танышу, сорауларга җавап, әсәрне анализлау, өлешләргә бүлү, эчтәлек сөйләү, план төзү | тест | | |
| 11 | С. Рәмиевнең тормыш юлы һәм иҗаты. “Мин”, “Син”, “Ул”, “Сызла, күңелем!” шигырьләре | 1 | С. Рәмиевнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. Шигырьләрне анализлау. | Уку, тыңлау, сүзлек эше, сорауларга җавап, биремнәр буенча эчтәлекне ачу | тест | | |
| **XX йөз әдәбияты** | | | | | | | |
| 12 | С. Хәким. “Җырларымда телим...”, “Клиндерләр эзлим” шигырьләре. М. Вәлиевнең “Әни” шигыре | 1 | Шагыйрь турында белгәннәрне искә төшерү. Шигырьләрнең эчтәлеген аңлау. | Сәнгатьле уку күнегүләре. Әниләр турында җырлар тыңлау, мөстәкыйль эшчәнлек | тест | | |
| 13 | Г. Афзалның тормыш юлы һәм иҗаты<br>Г. Афзалның “Юл газабы”, “Йөз кабат” шигырьләре. Лирика жанрлары | 1 | Автор турында белешмә бирү. Шигырьләр белән таныштыру. Лирика жанры турында сөйләү | Шагыйрь иҗаты буенча хронологик таблица төзү. Шигырьләрне уку. Сүзлек эше. Әдәби әсәргә анализ ясау | тест | | |
| 14 | М. Әгъләмовның тормыш юлы һәм иҗаты<br>М. Әгъләмовның “Каеннар илендә” шигыре | 1 | Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында өйрәнү<br>Шигырь эчтәлеге буенча әңгәмә | Презентация карау. Автор иҗаты буенча фикер алышу<br>Күргәзмәне карап, таныш китапларны табу. “Каеннар илендә” шигырен сәнгатьле уку, анализлау | тест | | |
| 15-16 | Ренат Харис. “Тукайның мәхәббәт төшләре”. Драма жанры | 2 | Авторның Тукайга багышланган әсәрен укып өйрәнү. Эчтәлеге буенча әңгәмә. Р. Харис иҗаты турында | Драма жанры турында төшенчә бирү. Тукай биографиясен искә төшерү. Тест эшләү. Иҗади эшчәнлек. | тест | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | язучылар фикере белән танышу | Сайлап уку күнегүләре | | | |
| **Драма жанры** | | | | | | | |
| 17-18 | Мирхәйдәр Фәйзинең тормыш юлы һәм иҗаты. “Галиябану” драмасы. Балтач районында М.Фәйзи музее | 2 | Драма жанры турында өйрәнүне дәвам итү. М. Фәйзи тормышы, иҗаты турында төшенчә бирү. Балтач районы Шода авылындагы музей белән танышу | Драма әсәрен дөрес уку. Эчтәлеге буенча әңгәмә. Һәр бүлек турында күзаллау булдыру. Музейлар белән фоторепортажлар аша танышу | тест | | |
| 19-20 | Т.Миңнуллинның тормыш юлы һәм иҗаты. Кама Тамагында Туфан Миңнуллин музее. СТУ. Язучының укытучы сайлаган, балалар яраткан бер әсәрен уку | 1 | Т. Миңнуллин иҗаты белән кызыксыну уяту. Авторның туган ягында оештырылган музее белән таныштыру | Драматург иҗаты буенча хронологик таблица төзү. Сәнгатьле уку, сорауларга җавап бирү | тест | | |
| **ХХ гасыр татар шигърияте** | | | | | | | |
| 21 | Татар шигърияте тарихы | 1 | ХХ гасыр татар шигърияте белән таныштыру | Укытучыны тыңлау. Таблица өстендә эш. Дәреслектә бирелгән текстны уку, сорауларга җавап | тест | | |
| 22 | Кыска шигырьләр. Р.Фәйзуллин. “Җаныңның ваклыгын сылтама заманга...” | 1 | Р.Фәйзуллинның кыска шигырьләре белән танышу. Шигырь эчтәлеген аңлау | Шигырьләрне сәнгатьле уку. Берьюллык шигырьләрдә мәгънәле кисәкне табу | тест | | |
| 23 | Г.Рәхим. “Тик мин” шигыре | 1 | Г.Рәхим иҗаты белән танышуны дәвам итү | “Тик мин” шигыре өстендә эш. Әсәр турында фикер алышу. Сораулар төзү | тест | | |
| 24 | Р.Гаташ. “Европада татар шагыйрьләре”, “Мин дөресен сөйлим” шигырьләре | 1 | Р.Гаташ иҗаты белән танышу. “Мин дөресен сөйлим” шигыре өстендә эш | Шигырьгә анализ, чылбыр буенча, тулысынча сәнгатьле уку. Эчтәлек буенча фикер алышу | тест | | |
| 25-26 | СТУ. Әниләр турында җырлар. Р.Миңнуллин. “Әнкәмнең догалары”; Р.Вәлиев. “Нигә, әни, нигә картаясың?”; М.Галиев. “Су буеннан әнкәй кайтып килә” шигырьләре | 1 | Әниләр турында шигырьләр уку, җырлар тыңлау. шагыйрьләрнең әсәрләре белән танышуны дәвам итү. Шагыйрьләр күтәргән теманы ачу. Ана образын тудыру | Шигырьләрне сәнгатьле уку, төркемнәрдә фикер алышу, сораулар һәм биремнәрне үтәү. Шагыйрь һәм композиторның уй-фикерләр уртаклыгын билгеләү | тест | | |
| 27 | Л. Шагыйрьҗан. “Татар шагыйренең бәясе” шигыре | 1 | Авторның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача белешмә бирү | Татар шагыйренә бирелгән бәя турында сөйләшү. Текст ахырындагы биремнәрне үтәү. | тест | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Сәнгатьле уку. Сүзлек эше | | | |
| 28 | Р. Зәйдулла. “Карап торам Казаныма” шигыре | 1 | Авторның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача белешмә бирү | Текст ахырындагы биремнәрне үтәү. Сәнгатьле уку. Казан турында белемнәрне тирәнәйтү | тест | | |
| **Татар хикәяләре** | | | | | | | |
| 29-30 | Ф. Латыйфи. “Аяклы каза” хикәясе | 1 | Ф. Латыйфи иҗатына күзәтү. “Аяклы каза” хикәясен укып анализлау | Хикәянең эчтәлеген аңлау, фикер алышу. Сораулар буенча эш | тест | | |
| 31-32 | Фаил Шәфигуллин. “Зәңгәр шугалак” | 1 | Ф. Шәфигуллин иҗатына күзәтү. “Зәңгәр шугалак” хикәясен укып анализлау | Хикәяне укып анализлау. Сорауларга җавап. Сәнгатьле уку күнекмәләре | тест | | |
| 33-34 | Г.Гыйльманов. “Яшел тутый” новелласы. Новелла жанры Л.Шагыйрьҗан. “Рухи икмәк”. Йомгаклау дәресе | 2 | Новелла жанры турында төшенчә бирү. Г.Гыйльманов иҗаты белән танышуны дәвам итү | “Яшел тутый” хикәясен сәнгатьле уку. Эчтәлеге буенча бер-берләренә сораулар бирү, җавапны тыңлау, бәяләү | тест | | |
| | | | | | | | |